**ГЛАВА
БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул.Центральная, 46, с.Большие Ачасыры,
Зеленодольский район, 422515**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**
**Үзәк урам, 46, Олы Ачасыр авылы,
Зеленодольск районы, 422515**

**Тел.факс: (84371) 2-56-47. E-mail: Bacr.Zel@tatar.ru, www.zelenodolsk.tatarstan.ru**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 11 нче гыйнвары №1

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча халык тыңлаулары билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге халкының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турындагы карар проектын халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, фикер алышуда катнашу, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып **карар итәм:**

1. Минем инициативам белән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә (№1 кушымта).
2. Билгеләү:
2.1. үткәрү датасы һәм вакыты - 2019 елның 11 феврале 16.00 сәгатьтә;
2.2. үткәрү вакыты 1 көн;

2.3. үткәрү урыны - Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 нчы йорт, авыл мәдәният йорты бинасы;

2.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы.

3. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составын раслау (2 нче кушымта).

4. Оештыру комитеты Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2018 елның 16 ноябрендәге 182 номерлы карары белән расланган ачык тыңлауларны (җәмәгать тыңлаулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә ачык тыңлаулар оештырырга һәм үткәрергә.

5. 2019 елның 18 гыйнварына кадәр әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы** **М.Г. Гатиятуллин**

Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгының
2019 елның 11 гыйнварындагы 1 нче
номерлы карарына 1 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

_________201_ ел №____

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында «2014 елның 1 июлендәге 191 номерлы Совет карары;

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 1 июлендәге 191 номерлы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 16 ноябрендәге 127 номерлы карары;

- 2018 елның 9 июлендә кабул ителгән 162 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2014 елның 1 июленнән кабул ителгән 191 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**

Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгының
2019 елның 11 гыйнварындагы 1 нче
номерлы карарына 2 нче кушымта

**Халык тыңлауларын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты**

| № п/п | Ф.И.О. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Гатиятуллин Марат Гумарович | җирлек башлыгы |
| 2. | Абзалутдинова Альфия Кабировна | Башкарма комитет сәркатибе |
| 3. | Гиниятуллина Фания Габбасовна | 1 нче округтан Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы депутаты |
| 4. | Минуллин Дамир Габбасович | 5 нче округтан Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы депутаты |
| 5. | Яруллина Гульнара Юнусовна | 7 нче округтан Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы депутаты |